**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**10.02.2022 ел** **№17-04**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында**
**вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча**
**Бердәм комиссия төзү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт кодексы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча Бердәм комиссия (алга таба - Бердәм конкурс комиссиясе) төзергә.
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе (алга таба - Бердәм аттестация комиссиясе) төзергә.
3. Кушымталарны расларга:

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Бердәм конкурс комиссиясе турында нигезләмә һәм аның составы;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе турында нигезләмә һәм аның составы.

4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә, муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча структур бүлекчәгә (штат расписаниесе нигезендә структур бүлекчәнең исеме) Бердәм конкурс комиссиясе һәм Бердәм аттестация комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aktanysh.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Э.Н. Фәттахов

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карары белән расланган
10.02.2022 ел №17-04

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Бердәм конкурс комиссиясе турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Бердәм конкурс комиссиясенең (алга таба - Комиссия) төп бурычларын һәм эш тәртибен билгели.

Комиссия Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм район җирлекләренең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә килешү буенча конкурс уздырырга хокуклы.

12. Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль район Советы карары белән раслана.

1.3. Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп формалаша.

1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль норматив-хокукый актларга таяна.

**2. Комиссиянең бурычлары**

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар оештыру һәм үткәрү.

**3. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары**

3. 1. Комиссия хокуклы:

дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга; комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә белгечләрне җәлеп итәргә; җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлекләрен оештыру белән бәйле тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр кертергә.

3.2. Комиссия бурычлы:

җирле үзидарә органнарына үткәрелә торган эш турында хәбәр итәргә.

**4. Комиссия эшен оештыру**

4.1. Комиссияне комиссия рәисе җитәкли, ә ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары.

4.2. Комиссия утырышлары кирәк саен уздырыла.

4.3. Комиссия утырышы аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булганда хокуклы.

4.4. Утырышның көн тәртибе һәм карар проектлары җаваплы секретар тарафыннан әзерләнә һәм барлык комиссия әгъзаларына утырышка кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

4.5. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.6. Комиссия утырышын аның рәисе яки вәкаләтле зат алып бара

4.7. Комиссия утырышына, аның әгъзаларыннан тыш, башка затлар да чакырылырга мөмкин. Утырышта катнашучылар составы комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

4.8. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләр комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе яисә аны алмаштыручы зат тарафыннан раслана. Утырыш беркетмәләре өч көн эчендә барлык комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган оешмаларга җибәрелә.

4.9. Утырыш беркетмәләрен алып бару, рәсмиләштерү һәм җибәрү комиссиянең җаваплы секретаренә йөкләнә.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карары белән расланган
10.02.2022 ел №17-04

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә Бердәм конкурс комиссиясе составы**

*Комиссия рәисе:*

| | |
|---|---|
| Фаттахов Э.Н. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башлыгы; |

*Комиссия рәисе урынбасарлары:*

| | |
|---|---|
| Вахитов И.Р. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе; |

*Комиссиянең җаваплы секретаре:*

| | |
|---|---|
| Сафина Л.Ф. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының кадрлар белән тәэмин итү секторы мөдире; |

*Комиссия әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Мосабиров Ш.А. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге җитәкчесе урынбасары; |
| | Конкурс игълан ителгән вакантлы вазыйфада, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесе (җирлек башлыгы), |
| | Бәйсез экспертлар (экспертларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә) |

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карары белән расланган
10.02.2022 ел №17-04

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
Бердәм аттестация комиссиясе турында нигезләмә

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясенең (алга таба - Комиссия) төп бурычларын һәм эш тәртибен билгели.

Комиссия Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм район җирлекләре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрне килешү буенча аттестацияләүне үткәрергә хокуклы.

1.2. Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карары белән раслана.

1.3. Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп формалаша.

1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль норматив-хокукый актларга таяна.

2. **Комиссиянең бурычлары һәм функцияләре**

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

җирле үзидарә органнары өчен, шул исәптән ведомство карамагындагы бүлекләр өчен кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрүне гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләүне үткәрүне оештыру;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең квалификация имтиханын үткәрүне оештыру;

2.2. Йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру максатларында комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрүне оештыра;

муниципаль хезмәткәрләргә класслы чин бирү өчен квалификация имтиханын үткәрүне оештыра.

3. **Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары**

3. 1. Комиссия хокуклы:

дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә комиссия эшенә белгечләрне җәлеп итәргә;

районның җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлеген оештыру белән бәйле тәкъдимнәр кертергә.

1.2 Комиссия бурычлы:

җирле үзидарә органнарына үткәрелә торган эш турында хәбәр итәргә.

4. **Комиссия эшен оештыру**

4.1. Комиссияне комиссия рәисе җитәкли, ә ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары.

4.2. Комиссия утырышлары кирәк саен уздырыла.

4.3. Комиссия утырышы аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булганда хокуклы.

4.4. Утырышның көн тәртибе һәм карар проектлары җаваплы секретаре тарафыннан әзерләнә һәм барлык комиссия әгъзаларына утырышка кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

4.5. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.6. Комиссия утырышын аның рәисе яки вәкаләтле зат алып бара.

4.7. Комиссия утырышына, аның әгъзаларыннан тыш, башка затлар да чакырылырга мөмкин. Утырышта катнашучылар составы комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә,

4.8. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләр комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе яисә аны алмаштыручы зат тарафыннан раслана. Утырыш беркетмәләре өч көн эчендә барлык комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган оешмаларга җибәрелә.

4.9. Утырыш беркетмәләрен алып бару, рәсмиләштерү һәм җибәрү комиссиянең җаваплы секретаренә йөкләнә.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карары белән расланган
10.02.2022 ел №17-04

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының**
**Бердәм аттестация комиссиясе составы**

*Комиссия рәисе:*

| | |
|---|---|
| Фаттахов Э.Н. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башлыгы; |

*Комиссия рәисе урынбасарлары:*

| | |
|---|---|
| Вахитов И.Р. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе; |

*Комиссиянең җаваплы секретаре:*

| | |
|---|---|
| Сафина Л.Ф. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының кадрлар белән тәэмин итү секторы мөдире; |

*Комиссия әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Мосабиров Ш.А. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге җитәкчесе урынбасары; |
| | Конкурс игълан ителгән вакантлы вазыйфада, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесе (җирлек башлыгы), |
| | Бәйсез экспертлар (экспертларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә) |